**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 18 июлендәге 2275 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Вахитов районында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1 – 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 128 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры 16:50:011711:421;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Вахитов районы;

билгеләүнең максаты: газ белән тәэмин итү системасының линия объектларын һәм аларның аерылгысыз технологик өлешләрен урнаштыру («Казан шәһәре, Тукай урамы, 66 йорттагы ГРП-15 техник яктан яңадан җиһазландыру»);

- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләүгә нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, «Газпром» гавами акционерлык җәмгыяте департаменты белән килештерелгән 2022-2028 елларга «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте эксплуатация-житештерү идарәсенең газ бүлү үткәргечләрен реконструкцияләү

программасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, милек хокукы Идел Буе районының бердәм җитештерү-технология комплексына теркәлгән (2001 елның 24 октябрендәге №16-50.3-23.2001-1046.1).

2. Сервитутны башкаруга бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаган яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт 1 ел тәшкил итә дип билгеләргә.

3. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1 – 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалану өчен материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

6.1. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, файдалану, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә;

6.2. үтәргә:

6.2.1. Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2023 елның 11 маендагы 1311 номерлы «Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән федераль әһәмияткә ия «Казан кремле ансамбле», XV гасыр – XX гасырның беренче чиреге

(Татарстан Республикасы (Татарстан)) мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, җирләрдән файдалануның махсус режимнарын һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында»гы әмере белән каралган чикләүләрне;

6.2.2. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 749-П номерлы «Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрен һәм сак предметын раслау турында»гы боерыгы белән каралган чикләүләрне үтәргә;

6.2.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 февралендәге 79 номерлы карары нигезендә чикләүләрне. Аның буенча территория «Казан шәһәре тарихи үзәгенең XI – XVIII гасырлар мәдәни катламы» истәлекле урыны рәвешендә федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан;


6.2.4. истәлекле урыннар территориясе чикләрендә проектлаштыруга, төзүгә һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга карата 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясеннән файдалану характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә хуҗалык эшчәнлегенә, проектлаштыруга һәм төзүгә таләпләр турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән билгеләнгән таләпләрне.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 18 июлендәге
2275 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең Вахитов районында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




| Масштаб 1:250<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| (розовый прямоугольник) | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| (синий контур) | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:011711 | кадастр кварталы |
| 16:50:011711:421 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр |